ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 май 2017 ел № 3178

Яр Чаллы моношәһәренең җиһазлар лизингын һәм социаль эшмәкәрлекне үстерү чаралары кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу һәм субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү тәртибе турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 октябрендәге 823 нче карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014-2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы, Башкарма комитетның 2016 елның 2 ноябрендәге 5770 нче карары белән расланган «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» программасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2016 елның 15 декабрендәге 13/5 нче карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы моношәһәренең җиһазлар лизингын һәм социаль эшмәкәрлекне үстерү чаралары кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу һәм субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә.А. Галиәкбәровага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 24 маендагы
3178 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы моношәһәренең җиһазлар лизингын һәм социаль эшмәкәрлекне үстерү чаралары кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу һәм субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү тәртибе

I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибе (алга таба – Тәртип) субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең (алга таба – муниципаль берәмлек) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алуны үткәрү тәртибен билгели.

2. Муниципаль берәмлекнең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү конкурентлы икътисадый мохитне үстерүдә кече һәм урта эшмәкәрлекнең ролен күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 31 октябрендәге 823 нче карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014-2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен, муниципаль берәмлеккә Татарстан Республикасы бюджетыннан керүче Татарстан Республикасының «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 93-ТРЗ санлы законында каралган акчалар хисабына һәм Башкарма комитетның 2016 елның 2 ноябрендәге 5770 нче карары белән расланган «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» программасында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә башкарыла.

3. Муниципаль берәмлекнең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына субсидия (алга таба – субсидия) рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү түбәндәге чараларны тормышка ашыру кысаларында бирелә:

1) җиһазлар лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының җиһазлар лизингы («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») килешүе буенча беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарын субсидияләү;

2) социаль эшмәкәрлекне үстерү: социаль юнәлештә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары – социаль эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарының бер өлешен субсидияләү.

4. Әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән чаралар кысаларында ярдәм күрсәтү өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу әлеге Тәртиптә билгеләнгән шартлар һәм сроклар нигезендә ярдәм күрсәтү өчен муниципаль берәмлекнең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе утырышларында гамәлгә ашырыла.

5. Әлеге Тәртиптә файдаланыла торган төп төшенчәләр:

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары (алга таба – эшмәкәрлек субъектлары) – «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге ФЗ-209 санлы Федераль законда билгеләнгән шартлар нигезендә кече предприятиеләргә, шул исәптән микропредприятиеләргә һәм урта предприятиеләргә кертелгән хуҗалык субъектлары (юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр);

Бюджет акчаларын алучы буларак төп эш башкаручы (алга таба – Вәкаләтле орган) – «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ;

Вәкаләтле оешма – үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турында» 2015 елның 4 мартындагы 132 нче карары нигезендә гамәлгә ашыручы һәм Вәкаләтле орган белән үзара эшчәнлек турында килешенү төзегән «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

социаль эшмәкәрлек – әлеге Тәртипнең 61 пунктында күрсәтелгән социаль проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының социаль җаваплы эшчәнлеге;

гариза бирүче – әлеге Тәртип таләпләре нигезендә субсидия алу хокукына ия эшмәкәрлек субъектларын билгеләү конкурс буенча сайлап алуда катнашуга конкурс гаризасы биргән эшмәкәрлек субъекты;

конкурс гаризасы – конкурс буенча сайлап алуда катнашу өчен әлеге Тәртип таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән документлар;

яна эшли башлаган эшмәкәрлек субъекты – конкурска гариза бирү вакытына теркәлү срогы бер елдан ким булган эшмәкәрлек субъекты;

гамәлдәге эшмәкәрлек субъекты – конкурска гариза бирү вакытына теркәлү срогы бер елдан артык булган эшмәкәрлек субъекты;

конкурс буенча сайлап алу – субсидия алу хокукына ия эшмәкәрлек субъектын билгеләү процедурасы;

конкурс комиссиясе – гариза бирүчеләрнең конкурс гаризаларын карап тикшерү һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән чаралар буенча субсидия алу хокукына ия эшмәкәрлек субъектларын ачыклау өчен Вәкаләтле орган тарафыннан төзелгән комиссия.

Конкурс буенча сайлап алу нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынучы затлар (шул исәптән конкурс буенча сайлау алуда катнашучы өчен конкурс гаризаларын тапшырган яки әлеге конкурс гаризаларын тапшырган оешмалар штатында торучы) яисә конкурс буенча сайлап алуда катнашучылар йогынты ясый ала торган затлар (шул исәптән гариза бирүчеләр эшендә катнашучылар (акционерлар), аларның идарә органнары әгъзалары, гариза бирүчеләрнең кредиторлары булган физик затлар) конкурс комиссиясе әгъзалары була алмый;

субсидия алучы – Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителүгә мөнәсәбәтле эшмәкәрлек субъекты;

муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы (алга таба – сәнәгать мәйданчыгы) – чикләрендә яңа призводстволар булдыру һәм аларны үстерү өчен уңайлы шартлар тудырыла торган бердәм чикләргә ия, мәйданы 20 мең кв. метрдан ким булмаган җир участогында урнашкан һәм бердәм оператор (идарәче компания) тарафыннан идарә ителә торган территориаль яктан аерымланган милекчелекнең барлык төр күчемсез мөлкәт объектлары;

сәнәгать мәйданчыгы резиденты – сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыручы эшмәкәрлек субъекты;

бизнес-инкубатор – эшчәнлекләренең башлангыч чорында эшмәкәрләргә ярдәм күрсәтү өчен төзелгән һәм мондый ярдәмне, урыннарны арендага бирү һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару өчен кирәкле хезмәт күрсәтү (шул исәптән консультация, бухгалтерлык һәм юридик хезмәтләр), шулай ук белем бирә торган тренинглар һәм семинарлар үткәрү юлы белән гамәлгә ашыручы оешма;

бизнес-инкубатор резиденты – бизнес-инкубатор территориясендә эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыручы эшмәкәрлек субъекты;

җиһазлар – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Амортизация төркемнәренә кертелә торган төп чаралар классификациясе турында» 2002 елның 1 гыйнварындагы 1 нче карары белән расланган Амортизация төркемнәренә кертелә торган төп чаралар классификациясенең икенче һәм аннан да югарырак амортизация төркемнәренә керүче җиһазлар, җайланмалар, механизмнар, транспорт чаралары (җиңел автомобильләрдән һәм һава судноларыннан тыш), станоклар, приборлар, аппаратлар, агрегатлар, машиналар (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан күпләп һәм ваклап сату эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җиһазлардан һәм элек эксплуатацияләнгән җиһазлардан тыш);

Порталдагы шәхси кабинет – гариза бирүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы uslugi.tatarstan.ru шәхси кабинеты;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (алга таба – Портал) – дәүләт хакимияте һәм ведомстводагы оешмалар, җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган электрон төрдәге хезмәтләр, шулай ук дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр турында мәгълүматларны үз эченә алган Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://uslugi.tatarstan.ru сайты төрендәге белешмә-мәгълүмат интернет-порталы;

мәгълүмат системасы – Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары күрсәтүгә вәкаләтләнгән оешмаларның эшчәнлеген автоматлаштыру, шулай ук ведомствоара эшчәнлектә катнашу процессларына мәгълүмати ярдәм күрсәтү өчен билгеләнгән «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасы;

электрон имза – электрон рәвештәге башка мәгълүматка (имзалана торган мәгълүматка) ялгана торган яки шундый мәгълүмат белән башка рәвешле бәйләнгән һәм мәгълүматны имзалаучы затны билгеләү өчен файдаланыла торган электрон рәвештәге мәгълүмат;

гади электрон имза – кодлар, парольләр яки башка чаралардан файдаланып, аерым зат тарафыннан электрон имза формалаштыру фактын раслаучы электрон имза.

## 2 бүлек. Субсидия алуга дәгъва иткән гариза бирүчеләргә таләпләр

6. Эшмәкәрлек субъекты түбәндәге шартлар бер үк вакытта үтәлгәндә субсидия алуга дәгъва итәргә хокуклы:

7. Гариза бирү вакытына эшмәкәрлек субъекты:

1) Түбәндәгеләр нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килгән очракта:

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге ФЗ-209 санлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының һәр категориясе өчен эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашырудан алынган керемнең чик күләмнәре турында» 2016 елның 4 апрелендәге 265 нче карары;

2) хуҗалык итүче субъект (юридик зат яки шәхси эшмәкәр) буларак теркәлгән очракта;

3) муниципаль берәмлек территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлеген гамәлгә ашырган очракта;

4) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, эшмәкәрлек субъектының Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр, шулай ук мәҗбүри пенсия һәм медицина

иминиятенә иминият взнослары буенча түләнмәгән бурычлары булмаган очракта;

5) эшмәкәрлек субъектының әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән чаралар буенча элек күрсәтелгән ярдәмгә бәйле, шул исәптән акчалардан файдалану һәм максатчан күрсәткечләргә ирешү турында хисап бирү буенча түләнмәгән бурычы булмау;

6) акцизлы товарлар житештерү һәм аларны сату, шулай ук файдалы казылмалар (гомуми таралган файдалы казылмалардан тыш) табу һәм аларны сату эшмәкәрлек субъекты эшчәнлегенең төп яки бер өстәмә төре булып тормаган очракта.

8. Субсидия бирүгә килешү төзү планлаштырылган айдан алдан килүче айның беренче числосына:

1) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә түләү срогы житкән, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм башка мәжбүри түләүләр, мәжбүри пенсия һәм медицина иминиятенә иминият взнослары буенча бурычлары булмау;

2) Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты каршында срогы чыккан башка бурычы булмау;

3) үзгәртеп оештырылу, ликвидацияләнү, банкротлык процессында булмау һәм хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләр булмау;

4) салым салуның ташламалы салым режимын бирүче һәм (яки) шундый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) үткәргәндә мәгълүматны ачыклау һәм бирүне күздә тотмаучы, теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория торган, устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше тулаем алганда 50 проценттан арткан чит ил юридик заты, шул исәптән Россия юридик заты булып тормау;

5) әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән чаралар буенча, башка норматив хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акчалар алмау.

## 3 бүлек. Субсидия бирүгә документлар әзерләү

9. Конкурс буенча сайлап алуда катнашу өчен эшмәкәрлек субъекты әлеге Тәртип таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән конкурс гаризасын кертергә тиеш.

10. Конкурс гаризасы кәгазьдә яисә гариза бирүченең Порталдагы шәхси кабинеты аша электрон төрдә бирелергә мөмкин («җиһаз лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының җиһаз лизингы

(«ЛИЗИНГ-ГАРАНТ») килешүе буенча беренче взнос (аванс) түләү чыгымнарын субсидияләү» чарасы буенча конкурс гаризасы биргән эшмәкәрлек субъектлары өчен).

11. Гариза бирү вакытында һәм килешү төзү максатында бирелә торган барлык документлар, шул исәптән Портал аша бирелә торган документлар тогәл итеп бастырылырга һәм аның барлык пунктлары да тутырылырга тиеш (мәгълүматлар булмаган очракта, сызык куела). Мөһер белән нығытылган (Россия Федерациясе законнарында мөһер булдыру бурычы билгеләнгән очракларда) һәм вәкаләтле зат имзасы (юридик затлар өчен) яки үз кулы белән таныкланган (шәхси эшмәкәрләр өчен) төзәтүләрдән тыш, бетерү һәм төзәтүләр рөхсәт ителми. Кәгазь төрдә бирелгән конкурс гаризасының барлык битләренә дә номерлар куелырга тиеш. Кәгазь төрдә бирелгән документларның күчермәләре моңа вәкаләт бирелгән зат имзасы һәм эшмәкәрлек субъекты мөһере белән таныкланган (юридик затлар өчен) (Россия Федерациясе законнарында мөһер булдыру бурычы билгеләнгән очракларда) яки үз кулы белән таныкланган (шәхси эшмәкәрләр өчен) булырга тиеш. Сканерланган күчермәләр рәвешендә портал аша бирелгән документлар моңа вәкаләт бирелгән затның гади электрон имзасы белән таныкланган булырга тиеш. Кәгазь төрдә бирелгән конкурс гаризасы тегелгән һәм моңа вәкаләт бирелгән зат имзасы һәм эшмәкәрлек субъектының мөһере белән таныкланган (юридик затлар өчен) (Россия Федерациясе законнарында мөһер булдыру бурычы билгеләнгән очракларда) яки, битләренең гомуми саны күрсәтелеп, конкурс гаризасының кире ягында үз кулы белән таныкланган (шәхси эшмәкәрләр өчен) булырга тиеш.

12. Конкурс гаризасы составында кирәкле документлар булмау, конкурс гаризасын тутыруга карата бу Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән таләпләр бозылу, гариза бирүче тапшыра торган документларда эшмәкәрлек субъектының бу Тәртипнең 7 пунктында каралган таләпләрне үтәвен раслый торган мәгълүматлар булмау, гариза бирүче тарафыннан бирелә торган документларда 50 пунктта каралган икътисадый эшчәнлек төрләренең төркемнәре һәм төркемчәләре буенча эшчәнлекнең төп һәм (яки) өстәмә төре гамәлгә ашырылуны яки эшмәкәрлек субъекты тарафыннан әлеге Тәртипнең 59 пунктында каралган шартларның берәрсе үтәлүне раслаучы мәгълүматлар булмау, тапшырылган мәгълүмат дөрес булмау эшмәкәрлек субъектын конкурс буенча сайлап алуда катнашучылар санына кертүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

13. Конкурс гаризасын әзерләү буенча барлык чыгымнарны да эшмәкәрлек субъекты түли.

14. Әлеге Тәртип һәм, әлеге Тәртип нигезендә тутырылырга тиешле документлар формасы турындагы мәгълүмат Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле орган сайтында урнаштырыла.

## 4 бүлек. Конкурс гаризасы составындагы документлар исемлеге

15. Конкурс гаризасы түбәндәге документларны үз эченә ала:

әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында каралганча, моңа вәкаләт бирелгән зат имзасы һәм эшмәкәрлек субъекты мөһере белән таныкланган (юридик затлар өчен) (Россия Федерациясе законнарында мөһер булдыру бурычы билгеләнгән очракларда) яки үз кулы белән таныкланган (шәхси эшмәкәрләр өчен) субсидия бирү турында гариза;

физик зат, шәхси эшмәкәр яки юридик зат житәкчесе паспортының тутырылган битләренең күчермәләре;

соңгы хисап датасына бухгалтерлык хисабы (бухгалтерлык балансы һәм финанс нәтиҗәләре турында хисап) (салым органының кабул итеп алу турында билгесен куеп яисә тиешле орган вазыйфаи затының электрон имзасы белән имзаланган электрон төрдәге хисаплылыкны кабул итү һәм тикшерү турында документлар теркәп тапшырыла) (агымдагы хисап чорында теркәлгән юридик затлардан (шәхси эшмәкәрләрдән) тыш) яки керемнәр һәм чыгымнар исәбен алу кенәгәсе («Бухгалтерлык хисабы турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә бухгалтерлык хисабын алып бармый торган эшмәкәрлек субъектлары өчен);

соңгы хисап датасына салым декларациясе (салым органының кабул итеп алу турында билгесен куеп яисә тиешле орган вазыйфаи затының электрон имзасы белән имзаланган электрон төрдәге хисаплылыкны кабул итү һәм тикшерү турында документлар теркәп тапшырыла) (агымдагы хисап чорында теркәлгән эшмәкәрлек субъектларыннан тыш);

соңгы хисап датасына Россия Федерациясе Пенсия фонды Идарәсенең «Иминиятләштерелгән затлар турында мәгълүматлар» формасын раслау турында» 2016 елның 1 февралендәге 83п санлы Карары белән расланган форма буенча иминиятләштерелгән затлар турында мәгълүматлар (пенсия фонды органнарының кабул итеп алу турында билгесен куеп яисә электрон цифрлы имзасы белән имзаланган электрон төрдәге хисаплылыкны кабул итү һәм тикшерү турында документлар теркәп тапшырыла) (агымдагы хисап чорында теркәлгән эшмәкәрлек субъектларыннан тыш);

гамәлгә кую документлары (юридик затлар өчен);

соңгы хисап датасына Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2007 елның 29 мартындагы ММ-3-25/174@ санлы боерыгы белән расланган форма буенча узган календарь ел өчен хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны турында мәгълүматлар (салым органының кабул итеп алу турында билгесен куеп яисә электрон цифрлы имзасы белән имзаланган электрон төрдәге хисаплылыкны кабул итү һәм тикшерү турында документлар теркәп тапшырыла) (агымдагы хисап чорында теркәлгән эшмәкәрлек субъектларыннан тыш);

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында каралганча, гариза бирүченең әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында, моңа вәкаләт бирелгән зат имзасы һәм эшмәкәрлек субъекты мөһере белән таныкланган (юридик затлар өчен) (Россия Федерациясе законнарында мөһер булдыру бурычы билгеләнгән очракларда) яки үз кулы белән таныкланган (шәхси эшмәкәрләр өчен) гарантия хаты;

субсидия бирү максатларыннан чыгып, әлеге Тәртипнең 53, 54 пунктларында билгеләнгән документлар.

Гариза бирүче, чит телдәге документларны билгеләнгән тәртиптә расланган рус теленә тәрҗемәсе белән бергә тапшыра.

16. Гариза бирүченең әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүе конкурс гаризасы составында бирелә торган документлар, шулай ук түбәндәге документлардагы мәгълүматлар нигезендә билгеләнә:

эшмәкәрлек субъектын дәүләти теркәү турында документ (ОГРН);

эшмәкәрлек субъектын салым исәбенә кую турында документ (ИНН);

конкурс гаризасы бирелә торган айның беренче числосына кадәр торышы буенча салым органыннан эшмәкәрлек субъектының, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, пеняләр, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән бурычлары булмавын раслаучы белешмә (Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ санлы боерыгы белән расланган форма буенча һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган);

конкурс гаризасы бирү датасына кадәр 30 календарь көннән артмаган срокта бирелгән һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган юридик затларның (шәхси эшмәкәрләрнең) Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Вәкаләтле оешма Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртип нигезендә күрсәтелгән документларны кабул итә.

Гариза бирүче шулай ук әлеге пунктта күрсәтелгән документларның тиешенчә расланган күчермәләрен Вәкаләтле оешмага тапшыру хокукына ия.

17. Гариза бирүчеләр тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеге өчен Россия Федерациясе законнарында каралганча җаваплы саналалар.

## 5 бүлек. Конкурс гаризаларын кабул итү һәм карап тикшерү

18. Гаризаларны кабул итү Вәкаләтле оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Конкурс гаризаларын кабул итү чоры вәкаләтле орган карары белән билгеләнә һәм 14 эш көненнән ким булырга тиеш түгел. Конкурс гаризаларын кабул итү чоры турында мәгълүмат конкурс гаризалары кабул ителә башлаган көнгә кадәр 3 эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

Үткәрелгән конкурс буенча сайлап алу йомгаклары нигезендә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре бүленеп беткән очракта, Вәкаләтле оешма конкурс гаризаларын кабул итүне гамәлгә ашырмый.

Вәкаләтле оешма түбәндәге очракларда конкурс гаризаларын кабул итүне яңадан башлап җибәрә:

агымдагы елда Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яки) федераль бюджет акчалары исәбеннән чараларны тормышка ашыруга өстәмә бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирелгәндә;

үткәрелгән конкурс буенча сайлап алу йомгаклары буенча әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән бюджет ассигнованиеләре тулысынча бүленмәгәндә;

субсидия алучылар субсидияләрне алудан баш тартканда (шәхси гариза яки әлеге Тәртипнең 37 пункты таләпләре нигезендә).

Гаризалар кабул итүне яңадан башлап җибәрү турындагы мәгълүмат конкурс гаризалары яңадан кабул итә башлаган көнгә 3 эш көне кала «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

19. Конкурс гаризасы кергән көнне Вәкаләтле оешма тарафыннан мәгълүмат системасында теркәлә.

20. Конкурс гаризалары мәгълүмат системасында теркәлгән көннән соң, эш көннәре белән исәпләнә торган 10 көн срокта, Вәкаләтле оешма тарафыннан әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килү предметына тикшерелә.

Вәкаләтле оешма эшмәкәрлек субъектына конкурс гаризаларын тикшерү нәтиҗәләре турында белдерү кәгазе җибәрә. Белдерү кәгазе әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тикшерү срогы узган көннән башлап, өченче эш көненнән дә соңга калмый җибәрелергә тиеш.

Гаризаны портал аша бирүчеләргә тикшерү нәтиҗәләре турында гариза бирүченең Порталдагы шәхси кабинеты аша хәбәр ителә.

Әлеге Тәртип таләпләренә туры килә торган конкурс гаризаларына «SWOT-анализ» стратегик планлаштыру методыннан файдаланып, Вәкаләтле оешма тарафыннан резюме әзерләнә.

21. Конкурс гаризасының конкурс буенча сайлап алуга кертелүе турындагы мәгълүмат, конкурс комиссиясенең чираттагы утырышы үткәрелүгә 3 эш көне кала «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

22. Конкурс буенча сайлап алу Вәкаләтле орган тарафыннан халык алдында башкарыла.

23. Вәкаләтле орган, конкурс комиссиясе утырышы үткәрелә торган көнгә 3 эш көненнән дә соңга калмый, утырыш үткәрелү датасы һәм вакыты

турындагы мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында бастырып чыгара.

24. Исемлек буенча составының яртысыннан артыгы катнашкан очракта, конкурс комиссиясенең утырышы тулы хокуклы санала.

25. Конкурс комиссиясе утырышының ачык булуы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында онлайн-трансляция үткәрү юлы белән тәэмин ителә.

26. Конкурс гаризалары конкурс комиссиясе утырышында гариза бирүче-юридик затның житәкчесе яки гариза бирүче-шәхси эшмәкәр яки законнар нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч язуы буенча аларның вәкиле катнашында карала. Конкурс гаризалары конкурс буенча сайлап алуга кертелгән беренче конкурс гаризасыннан башлап мәгълүмат системасындагы гаризалар реестры нигезендә берәмләп карала.

27. Гариза бирүче-юридик зат житәкчесенең яки гариза бирүче-шәхси эшмәкәрнең яки аларның вәкиленең килүе мәжбүри дип таныла. Алар килмәгән очракта, конкурс гаризасы каралмый һәм конкурс комиссиясе тарафыннан субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

28. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының жиһаз лизингы («ЛИЗИНГ-ГАРАНТ») килешүе буенча беренче взнос (аванс) түләү чыгымнарын субсидияләү хокукына ия эшмәкәрлек субъектларын билгеләгәндә, конкурс комиссиясе әгъзалары конкурс буенча сайлап алуның түбәндәге критерийларына таяна:

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Проектның эшләнү дәрәжәсе | 1-5 балл |
| 2 | Проектны тормышка ашыруның икътисадый нәтиҗәләлеге | 1-5 балл |
| 3 | Социаль-икътисадый күрсәткечләргә ирешү | 1-5 балл |
| 4 | Ихтыяж булу | 1-5 балл |
| 5 | Импортны алмаштыру | 1-5 балл |

Социаль эшмәкәрлекне үстерүгә субсидия алу хокукына ия эшмәкәрлек субъектларын билгеләгәндә, конкурс комиссиясе әгъзалары конкурс буенча сайлап алуның түбәндәге критерийларына таяна:

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Проектның эшләнү дәрәҗәсе | 1 - 5 балл |
| 2 | Проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте | 1 - 5 балл |
| 3 | Конкурентлык сәләте | 1 - 5 балл |
| 4 | Ихтыяж булу | 1 - 5 балл |
| 5 | Икътисадый максатчанлык | 1 - 5 балл |

29. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурс гаризаларын конкурс буенча сайлап алуның һәр критерие буенча таләпләр нигезендә 5 баллы шкала (1 дән 5 кадәр) буенча бәяли.

Эш урыннары буенча максатчан күрсәткечкә ирешүне планлаштырган эшмәкәрлек субъектларына өстәмә балл 4 берәмлектән күбрәк бирелә.

Конкурс комиссиясе конкурс гаризалары 12 баллдан да ким бәяләнмәүдән чыгып, эшмәкәрлек субъектларының субсидия алу хокукына ия булуларын билгели. Шулай ук, уңай хәл ителә торган гаризалар саны Башкарма комитетның 2016 елның 2 ноябрендәге 5770 нче карары белән расланган «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» программасында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

30. Конкурс гаризаларын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе түбәндәге карарларны чыгара:

бюджет ассигнованиеләре лимитлары чикләрендәге субсидияне алу хокукына ия катнашучыларны билгеләү турында;

бюджет ассигнованиеләре лимитлары чикләренә керми торган субсидияне алу хокукына ия катнашучыларны билгеләү турында;

субсидия алу хокукына ия булмаган катнашучыларны билгеләү турында.

31. Конкурс комиссиясе карарлары конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан алып барыла торган Беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмә конкурс комиссиясе утырышы үткәрелгән көнне конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан раслана.

31. Беркетмә конкурс комиссиясе утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, конкурс комиссиясенең катнашкан әгъзалары, каралган гаризалар саны, эшмәкәрлек субъектлары дәгъва итәргә хокуклы булган субсидия суммасын күрсәтеп, конкурс гаризаларын карап тикшерү нәтиҗәләре, субсидия бирү кире кагылган катнашучылар буенча субсидия суммасы турындагы мәгълүматлардан тора.

33. Беркетмә, расланган көннән соң 3 эш көне эчендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

34. Портал аша гариза биргән гариза бирүчеләргә, өстәмә рәвештә гариза бирүченең Порталдагы шәхси кабинеты аша конкурс нәтиҗәләре турында хәбәр ителә.

35. Гариза бирүче билгеләнгән тәртиптә яңа конкурс гаризасы белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Портал аша бирелгән гаризалар электрон төрдә Вәкаләтле оешмада һәм Вәкаләтле органда саклана.

Гариза бирүче тарафыннан кәгазь төрдә бирелгән гаризалар Вәкаләтле органда саклана. Гариза бирүче кәгазь төрдә биргән документларын кире алырга хокуклы.

## 6 бүлек. Субсидияләр бирү тәртибе

36. Субсидия бирү өчен 5 нче кушымта нигезендә Вәкаләтле орган һәм субсидия алучы арасында төзелә торган субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзелә.

Килешүдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, финанс белән тәэмин итү чыганагын субсидия тәшкил иткән чыгымнарның юнәлешләре, субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең (максатчан күрсәткечләренең) зурлыгы, субсидияне күчерү тәртибе, субсидиядән файдалану һәм субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә (максатчан күрсәткечләргә) ирешү турында хисап бирү сроклары һәм формалары, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыкларын субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары, югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлаштыручы эшләнмәләр сатып алганда (кайтарганда), Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаларны бирү максатына ирешүгә бәйле банка операцияләрдән тыш, алынган акчалар хисабына чит ил валютасы сатып алуны тыю турында нигезнамә, субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү максатлары һәм тәртибе үтәлешен, субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларының үтәлеше турында нигезнамә үтәлешен Вәкаләтле оешма, Вәкаләтле орган һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүне гамәлгә ашыруга субсидия алучының ризалыгы карала.

37. Эшмәкәрлек субъекты әлеге Тәртипнең 3 пунктының 1-2 пунктларында күрсәтелгән чаралар буенча Беркетмә расланган көннән соң, эш көннәре белән исәпләнә торган 30 көн срокта, әлеге Тәртип таләпләре нигезендә субсидия бирү турында килешү төзү өчен кирәкле документларны Вәкаләтле органга тапшыра.

Килешү төзү өчен кирәкле документлар әлеге Тәртипнең 11 пунктына туры китереп рәсмиләштерелергә тиеш.

Эшмәкәрлек субъекты тарафыннан әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән таләпләр үтәлмәгән очракта, Конкурс комиссиясе тарафыннан чыгарылган уңай карар юкка чыгарылган санала.

38. Килешү төзү өчен кирәкле документлар, алар кергән көнне Вәкаләтле орган тарафыннан мәгълүмат системасында теркәлә.

Килешү төзү өчен кирәкле документларның сканерланган күчермәләре, алдан тикшерү өчен, гариза бирүченең порталдагы шәхси кабинеты аша электрон төрдә җибәрелергә мөмкин («җиһазлар лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының җиһазлар лизингы

(«ЛИЗИНГ-ГРАНТ») килешүе буенча беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарын субсидияләү» чарасы буенча субсидия алуга дәгъва иткән эшмәкәрлек субъектлары өчен).

Килешү төзү өчен кирәкле документлар теркәлгәннән соң, эш көннәре белән исәпләнә торган 10 көн срокта, Вәкаләтле орган тарафыннан алар әлеге Тәртиптә куелган таләпләргә туры килү предметына тикшерелә. Вәкаләтле орган эшмәкәрлек субъектына тикшерү нәтиҗәләре турында белдерү кәгазе җибәрә. Белдерү кәгазе тикшерү срогы чыккан көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмый җибәрелергә тиеш.

Документлар Тәртип таләпләренә тулысынча туры килгән очракта, Вәкаләтле орган, тикшерү срогы чыккан көннән соң эш көннәре белән исәпләнә торган өч көн срокта, субсидия бирү турында карар кабул итә.

Карар, карарны чыгару датасы, вакыты һәм урыны, карар чыгуга мөнәсәбәтле эшмәкәрлек субъектының исеме, бирелә торган субсидиянең суммасы турында мәгълүматны үз эченә ала.

Җитешсезлекләр булган очракта, эшмәкәрлек субъектына Беркетмә расланган көннән соң, эш көннәре белән исәпләнә торган 30 көн срокта, аларны төзәтү хокукы бирелә. Алар бетерелмәгән очракта, Конкурс комиссиясе тарафыннан чыгарылган карар юкка чыгарылган санала.

39. Вәкаләтле орган һәм Вәкаләтле оешма субсидия алучыга карата килешү төзү өчен әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрдән тыш башка таләпләр куя алмый.

40. Вәкаләтле орган субсидияне максатчан файдалану һәм килешүдә күрсәтелгән максатчан күрсәткечләргә ирешү турында мәгълүмат бирүне контрольдә тота.

41. Субсидиядән файдалану турындагы хисаплылык эшмәкәрлек субъекты тарафыннан Вәкаләтле органга тапшырыла.

Хисаплылык формалары, субсидиядән файдалану турында хисаплылык бирү тәртибе һәм сроклары килешүдә билгеләнә.

42. Вәкаләтле органның килешүгә үзгәрешләр кертүгә бәйле карарлары, дәүләт ярдәме алган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бизнес-проектларны тормышка ашыру процессында барлыкка килгән мәсьәләләрне карап тикшерү буенча Комиссия утырышы беркетмәләре нигезендә кабул ителә. Күрсәтелгән комиссия составы һәм аның эш тәртибе Вәкаләтле орган тарафыннан раслана.

43. Субсидияләр, керү срокларын һәм, бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрен исәпкә алып, килешү төзү өчен кирәкле документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул ителгән көннән соң, эш көннәре белән исәпләнә торган 10 көн срокта, субсидия алучының Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган шәхси счетына акча күчерү юлы белән, Вәкаләтле орган тарафыннан бирелә.

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелүче акчалар финанс белән тәэмин итү чыганагы булган юридик затларның

чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә муниципаль бюджеттан бирелә торган субсидияләргә бәйле операцияләр, муниципаль берәмлекнең финанс органы мөрәҗәгате нигезендә, Федераль казначылыкның территориаль органнарында күрсәтелгән субсидияләрне алучыларга – юридик затларга ачылган шәхси счетларда чагылырга тиеш. Субсидия алучыга шәхси счет Федераль казначылыкның территориаль органында бюджет процессында катнашучы булып тормаган юридик затларның (аларның аерымланган бүлекчәләренең) акчалары белән операцияләрне исәпкә алу өчен ачыла.

Субсидия, субсидия алучының акча йөкләмәсен түләү өчен түләү документлары субсидия алучы тарафыннан Федераль казначылыкның территориаль органына тапшырылганнан соң икенче эш көненнән дә соңга калмый күчерелә.

44. Түбәндәге очракларда бирелгән субсидияләр, субсидия алучы Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң, эш көннәре белән исәпләнә торган 10 көн срокта, муниципаль берәмлек бюджеты keremенә кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән шартлар бозылу фактлары ачыклану;

Вәкаләтле оешма тарафыннан Вәкаләтле органга документларда күрсәтелгән дөрес булмаган мәгълүматлар бирелү;

календарь ел нәтиҗәләре буенча, килешүдә каралган бизнес-проектны тормышка ашыруның максатчан күрсәткечләренең кимендә 20 процентына ирешмәү.

Хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан субсидиянең файдаланылмый калган өлеше булган очракта, хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, ул муниципаль берәмлек керемөнә кире кайтарылырга тиеш.

Вәкаләтле орган һәм финанс контроле органы законнарда каралган тәртиптә, субсидия алучылар тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә тикшерү үткәрә.

Субсидия алучы тарафыннан субсидия акчаларын кире кайтару өчен билгеләнгән срок бозылган очракта, Вәкаләтле орган әлеге пунктның беренче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән сроклар тәмамланган көннән соң, календарь көннәр белән исәпләнә торган 30 көн срокта, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, муниципаль берәмлек бюджетына субсидияне кире кайтару буенча чаралар күрә.

45. Субсидияне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

46. Гариза бирүче, Вәкаләтле орган һәм Вәкаләтле оешма вазыйфаи затларының эш итүләреннән (эш итмәүләреннән) риза булмыйча, законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

7 бүлек. Җиһазлар лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының җиһазлар лизингы («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») килешүе буенча беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарын субсидияләү

47. Чараның максаты булып эшмәкәрлек субъектларының җиһазлар лизингы килешүе буенча беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарын субсидияләү тора.

Финанс арендасы (лизинг) килешүе буенча беренче взнос (аванс) – лизинг түләүләре графигында билгеләнгән һәм мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты буенча лизинг предметын фактта алу моментына кадәр, финанс арендасы (лизинг) килешүе буенча эшмәкәрлек субъекты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган түләү (түләүләр).

48. Субсидияләр лизинг килешүе төзегән һәм икътисад эшчәнлегенең өстенлекле төрләре буенча бизнес-проектларны тормышка ашыручы эшмәкәрлек субъектларына бирелә.

Лизинг бирүче белән лизинг килешүләре конкурс гаризасы бирү моментына гамәлдә булырга тиеш.

49. Лизинг бирүче – җәлеп ителгән яки үз акчалары хисабына лизинг килешүен тормышка ашыру барышында милеккә җиһаз сатып алучы һәм аны лизинг предметы сыйфатында эшмәкәрлек субъектына бирүче юридик зат. Лизинг бирүче түбәндәге шартларга туры килергә тиеш:

1) Россия Федерациясе резиденты статусы булу;

2) мөлкәтне финанс арендасына (лизингка) бирүне гамәлгә кертү документларында эшчәнлекнең төп төре буларак күрсәтү;

3) эшмәкәрлек субъектларына мөлкәтне финанс арендасына (лизингка) бирү өлкәсендә өч елдан ким булмаган эш стажы булу;

4) эшмәкәрлек субъектлары белән төзелгән финанс арендасы (лизинг) килешүләренең формалаштырылган портфеле булу, эшмәкәрлек субъектлары белән эшләүнең махсуслаштырылган технологияләре (программалары) булу;

5) лизинг алучы – эшмәкәрлек субъектының финанс торышын бәяләү буенча расланган Методикасы булу;

6) соңгы хисап датасына чиста активлар кыйммәтенең уңай зурлыклары булу (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Чиста активлар кыйммәтен билгеләү тәртибен раслау турында» 2014 елның 28 августындагы 84н санлы Боерыгы белән расланган Методика буенча);

7) соңгы хисап датасына 40 млн. сумнан ким булмаган чиста активлар кыйммәтенең зурлыгы (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Чиста активлар кыйммәтен билгеләү тәртибен раслау турында» 2014 елның 28 августындагы 84н санлы Боерыгы белән расланган Методика буенча), яисә соңгы хисап датасына устав капиталының зурлыгы 15 млн. сумнан ким булмау, яисә банк операцияләрен гамәлгә ашыруга гамәлдәге лицензиясе булган кредит оешмасының лизинг бирүчесенең илле проценттан артык өлеше устав капиталында катнашу.

Лизинг бирүченең әлеге таләпләргә туры килүен раслаучы документлар ел саен лизинг бирүче тарафыннан Вәкаләтле оешмага бирелә.

Әлеге таләпләргә туры килүне раслау йомгаклары буенча, лизинг бирүче мәгълүмати үзара эшчәнлек турында Вәкаләтле оешма һәм Вәкаләтле орган белән очьяклы килешенү төзи.

Әлеге таләпләргә туры килүләрен раслаучы документларын Вәкаләтле оешмага тапшырмаган лизинг компанияләре белән лизинг килешүе төзегән гариза бирүчеләрне конкурста сайлап алуга кертү кире кагыла.

50. Субсидияләр бизнес-проектны тормышка ашыручы һәм, топ һәм (яки) остәмә эшчәнлекләрен икътисадый эшчәнлекнең түбәндәге төркемнәре һәм төркемчәләре буенча (Техник җайга салу һәм метрология буенча Федераль агентлыкның 2014 елның 31 гыйнварындагы 14-ст санлы боерыгы белән кабул ителгән Икътисадый эшчәнлек торләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД 2) ОК 029-2014 (КДЕС 2 нче ред.) нигезендә) гамәлгә ашыручы эшмәкәрлек субъектларына бирелә:

| | |
|---|---|
| 01.1 | Берьеллык культуралар үстерү |
| 01.2 | Күпьеллык культуралар үстерү |
| 01.3 | Үрентеләр үстерү |
| 01.4 | Терлекчелек |
| 01.5 | Катнаш авыл хуҗалыгы |
| 02.1 | Урманчылык һәм башка урман хуҗалыгы эшчәнлеге |
| 02.2 | Агач хәзерләү |
| 02.3 | Ашарга яраклы урман ресурслары, агач булмаган урман ресурслары һәм дару үләннәре җыю һәм хәзерләү |
| 03.2 | Балык үрчетү |
| 10 | Азык-төлек продуктлары җитештерү |
| 11 | Эчемлекләр җитештерү |
| 13 | Текстиль эшләнмәләр җитештерү |
| 14 | Ос киемнәре җитештерү |
| 15 | Тире һәм тире эшләнмәләре җитештерү |
| 16 | Агач эшкәртү һәм агач һәм бөке эшләнмәләре (йорт җиһазларыннан тыш) җитештерү, саламнан һәм үрә торган материаллардан эшләнмәләр җитештерү |

| | |
|---|---|
| 17 | Кәгазь һәм кәгазь эшләнмәләр җитештерү |
| 20 | Химик матдәләр һәм химия продуктлары җитештерү |
| 21 | Дару чаралары һәм медицина максатларында кулланыла торган материаллар җитештерү |
| 22 | Резин һәм пластмасса эшләнмәләр җитештерү |
| 23 | Металл булмаган башка минераль продукция җитештерү |
| 24 | Металлургия җитештерүе |
| 25 | Әзер металл эшләнмәләр (машиналардан һәм җиһазлардан тыш) җитештерү |
| 26 | Компьютерлар, электрон һәм оптик эшләнмәләр җитештерү |
| 27 | Электр җиһазлары җитештерү |
| 28 | Башка төркемчәләргә кертелмәгән машиналар һәм җиһазлар җитештерү |
| 29 | Автотранспорт чаралары, тагылмалар һәм ярымтагылмалар җитештерү |
| 30 | Башка транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерү |
| 31 | Йорт җиһазлары җитештерү |
| 32 | Башка әзер әйберләр җитештерү |
| 38 | Калдыклар җыю, эшкәртү һәм утильләштерү; икенчел чимал эшкәртү |
| 39 | Пычратулардан салынган зыяннарны бетерү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү һәм калдыкларны юкка чыгаруга бәйле булган башка хезмәтләр күрсәтү |
| 49.31 | Коры җир пассажир транспорты эшчәнлеге: шәһәр эчендә һәм шәһәр янында пассажирлар йөртү (табигый газ (метан) белән эшли торган автотранспорт чаралары сатып алынган очракта) |
| 49.41 | Йөк автомобиль транспорты эшчәнлеге (табигый газ (метан) белән эшли торган автотранспорт чаралары сатып алган очракта) |

51. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Амортизация төркемнәренә кертелә торган төп чаралар классификациясе турында» 2002 елның 1 гыйнварындагы 1 нче карары белән расланган Амортизация төркемнәренә кертелә торган төп чаралар классификациясенең икенче һәм аннан да

югарырак амортизация төркемнәренә керүче җиһазлар, җайланмалар, механизмнар, транспорт чаралары (җиңел автомобильләрдән һәм һава судноларыннан тыш), станоклар, приборлар, аппаратлар, агрегатлар, машиналар лизинг килешүе предметы булырга мөмкин.

Түбәндәгеләр лизинг килешүе предметы була алмый:

эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан күпләп һәм ваклап сату эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җиһазлар;

элек эксплуатацияләнгән җиһазлар.

52. Субсидия күләме:

1) яңа эшли башлаган эшмәкәрлек субъектлары өчен – җиһазлар лизингы килешүен төзегәндә беренче взносны (аванс) түләүгә максатчан чыгымнарны өлешчә финанслау шартларында лизинг килешүе суммасының 45 проценты күләмендә, әмма бер алучыга 1 млн. сумнан артмаган күләмдә;

2) гамәлдәге эшмәкәрлек субъектлары өчен – лизинг килешүе буенча аванс түләвен кертү буенча фактта тотылган чыгымнарны каплауга лизинг килешүе суммасының 30 проценты күләмендә, әмма бер алучыга 3 млн. сумнан артмаган күләмдә;

3) яңа эшли башлаган эшмәкәрлек субъектлары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 елның 27 августындагы 616 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында аккредитация алган бизнес-инкубаторлар резидентлары өчен – лизинг килешүе буенча аванс түләвен кертү буенча фактта тотылган чыгымнарны каплауга лизинг килешүе суммасының 50 процентыннан артмаган һәм бер алучыга 1 млн. сумнан артмаган күләмдә;

4) гамәлдәге эшмәкәрлек субъектлары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 елның 27 августындагы 616 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында аккредитация алган сәнәгать мәйданчыклары резидентлары өчен – лизинг килешүе буенча аванс түләвен кертү буенча фактта тотылган чыгымнарны каплауга лизинг килешүе суммасының 50 процентыннан артмаган һәм бер алучыга 3 млн. сумнан артмаган күләмдә.

53. Әлеге бүлек таләпләре нигезендә субсидия алуга дәгъва иткән эшмәкәрлек субъекты гариза биргәндә, әлеге Тәртипнең 15 пунктында күрсәтелгән документларга өстәп, түбәндәге документларны тапшыра:

яңа эшли башлаган эшмәкәрлек субъектлары өчен:

лизинг килешүенең төп параметрларын күрсәтеп, субсидия бирү шарты үтәлгәндә лизинг килешүе төзү турында лизинг бирүче тарафыннан имзаланган гарантия хаты;

бизнес-проектны тормышка ашыруга кагылышлы документлар;

биналары яки җир участоклары булуны раслый торган документларның күчермәләре;

проектны тормышка ашыру өчен кирәкле гамәлдәге контрактларның (булганда) күчермәләре;

лицензияләр һәм рөхсәт язуларының, патентлар, фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләренең, эксперт бәяләмәләренең һәм башкаларның (булганда) күчермәләре;

әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендә бизнес-проект паспорты;

гамәлдәге эшмәкәрлек субъектлары өчен:

түбәндәгеләрнең лизингка бирүче тарафыннан расланган күчермәләре:

төп параметрларны күрсәтеп төзелгән лизинг килешүе;

җиһазлар сатып алу-сату килешүе һәм лизинг килешүе буенча аванс күчерүе турындагы түләү хакында банк билгесе куелган түләү йөкләмәсенең (булганда) эшмәкәрлек субъекты тарафыннан таныкланган күчермәсе;

бизнес-проектны тормышка ашыруга кагыла торган документлар;

биналары яки җир участоклары булуны раслый торган документлар;

проектны тормышка ашыру өчен кирәкле гамәлдәге контрактларның (булганда) күчермәләре;

лицензияләр һәм рөхсәт язуларының, патентлар, фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләренең, эксперт бәяләмәләре һәм башкаларның (булганда) күчермәләре;

әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендә бизнес-проект паспорты.

54. Сәнәгать мәйданчыгы резидентлары әлеге Тәртипнең 15 һәм 53 пунктларында күрсәтелгән документларга өстәп, түбәндәге документларны тапшыралар:

резидентның сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшчәнлек алып баруы турында сәнәгать мәйданчыгының идарәче компаниясе белән төзелгән килешү күчермәсен яисә гариза бирүченең сәнәгать мәйданчыгы резиденты булуын раслый торган идарәче компания хаты (резидентлар реестрыннан өземтә);

субсидия бирелгән очракта, резидентның бер календарь ел эчендә җиһазларны сәнәгать мәйданчыгы территориясендә урнаштыру һәм алардан файдалану турындагы гарантия хаты.

55. Бизнес-инкубаторлар резидентлары, әлеге Тәртипнең 15 һәм 53 пунктларында күрсәтелгән документларга өстәп, дәүләт милкәтен арендалау килешүенең күчермәсен тапшыра.

56. Әлеге бүлек таләпләре нигезендә субсидия алуга дәгъва иткән эшмәкәрлек субъекты әлеге Тәртипнең 37 пунктында каралган тәртиптә, Вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

лизингка бирүче тарафыннан таныкланган лизинг килешүенең һәм аванс түләүләре өчен счетның күчермәләре (яңа эшли башлаган эшмәкәрлек субъектлары өчен);

лизингка бирүче тарафыннан таныкланган лизинг килешүенең, аванс түләүләрен түләү фактын раслаучы документларның (түләү йөкләмәләренең, түләү таләпләренең яки түләү фактын раслаучы һәм банкның түләү турында билгесе (банк хезмәткәренең имзасы һәм банк штампы) куелган башка документларның) күчермәләре (гамәлдәге эшмәкәрлек субъектлары өчен);

гариза бирүченең әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры туры килүе турында, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында каралганча, моңа вәкаләт бирелгән зат имзасы һәм эшмәкәрлек субъекты мөһере белән таныкланган (юридик затлар өчен) (Россия Федерациясе законнарында мөһер булдыру бурычы билгеләнгән очракларда) яки үз кулы белән таныкланган (шәхси эшмәкәрләр өчен) гарантия хаты.

## 8 бүлек. Социаль эшмәкәрлекне үстерү

57. Эшчәнлекнең социаль әһәмияткә ия төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү һәм аларны үстерү чараның максаты булып тора.

58. Тәэмин итү чыганакларын субсидия тәшкил иткән чыгымнарның юнәлешләре булып, җиһаз, махсус инвентарь, оргтехника һәм программа чаралары (алга таба – товар) сатып алуга тотылган чыгымнар, бизнес-проект юнәлеше нигезендә производство проектлаштыруы, дизайн, сертификатлаштыру һәм стандартлаштыру, персоналны укыту һәм әзерләүгә (алга таба – хезмәтләр) тотылган чыгымнар тора.

59. Субсидияләр түбәндәге шартларның берәрсе үтәлүне тәэмин итүче эшмәкәрлек субъектларына бирелә:

Эшмәкәрлек субъектлары хезмәткәрләре арасыннан гражданнарның түбәндәге категорияләренең исемлек буенча уртача саны 50 процenttан ким булмаган, ә шундый хезмәткәрләрнең хезмәт хакы түләү фондындагы өлеше 25 проценттан ким булмаган күләмдә тәшкил итә:

инвалидлар;

өлкән яшьтәге гражданнар (60 яшьтән өлкән ир-атлар һәм 55 яшьтән өлкән хатын-кызлар);

7 (җиде) яшькә кадәр балалары булган хатын-кызлар;

ятимнәр;

балалар йортыннан чыгарылучылар;

конкурс гаризасы бирү датасыннан алда килгән 2 (ике) ел дәвамында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар.

60. Социаль эшмәкәрлек субъекты эшчәнлекнең түбәндәге өлкәләрендә хезмәтләр күрсәтү (товарлар җитештерү, эшләр башкару) буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыралар:

- гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренә керүче затларның мәшгульлегенә һәм үзмәшгульлегенә булышлык итүне кертеп, һөнәри ориентациягә һәм эшкә урнаштыруга ярдәм күрсәтү;

- гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренә керүче затларга һәм балалы гаиләләргә сәламәтлек саклау, физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтү, балалар һәм яшьләр өчен түгәрәкләрдә, секцияләрдә, студияләрдә дәресләр үткәрү;

- социаль туризм оештыру – гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренә керүче затлар өчен бары тик экскурсия-танып белү өлешендә;

- медицина техникасы, протез-ортопедия эшләнмәләре, шулай ук инвалидлыкны профилактикалау яки инвалидларны терапевтик реабилитацияләү өчен генә файдаланылырга мөмкин булган материалларны, автомототранспортны кертеп, техник чаралар җитештерү һәм (яки) сату;

- мәдәни-агарту эшчәнлеген (музейлар, театрлар, мәктәп-студияләр, музыка учреждениеләре, иҗат мастерскойлары) тәэмин итү;

- гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренә керүче затларга белем бирү хезмәтләре күрсәтү;

- гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренә керүче затларны, шулай ук 2 (ике) ел дәвамында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны һәм, наркомания һәм алкоголизмнан интегүче затларны социаль-актив эшчәнлеккә җәлеп итүдә ярдәм күрсәтү.

61. Гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренә түбәндәгеләр керә:

- Бөек Ватан сугышында яки дәүләттән читтә хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан гражданнар;

- сугыш вакытында балигъ булмаган яшьтә эләккән фашизм тоткыннары;

- тыл хезмәтчәннәре яки Бөек Ватан сугышы вакытындагы казанышлары өчен Советлар Союзы медале (ордены) булган кешеләр;

- авария, бәла-каза, сугыш нәтиҗәсендә яшәү урыны тору өчен яраксыз хәлгә килгән яки аны югалткан затлар;

- ата-анасыз (попечительсез) калган балалар, шулай ук тәрбиягә алынган балалар;

- 1-3 төркем инвалидлар категориясенә кергән гражданнар, шулай ук шундый балаларның ата-аналары;

- 5 һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләр;

- хезмәт ветераны саналган һәм тиешле раслау документлары булган затлар;

- балаларын мөстәкыйль тәрбияләүче аналар.

62. Субсидияләр, ала торган субсидия суммасының 15% ыннан ким булмаган күләмдә чыгымнарны финанслауны тәэмин иткән социаль эшмәкәрлек субъектына чыгымнарны каплау өчен, 500 000 (биш йөз мең)

сумнан артмаган, әмма бизнес-проектның тулы кыйммәтенең 85 процентыннан артмаган күләмдә бирелә.

63. Әлеге бүлек таләпләре нигезендә субсидия алуга дәгъва иткән эшмәкәрлек субъекты гариза биргәндә, әлеге Тәртипнең 15 пунктында күрсәтелгән документларга өстәп, түбәндәге документларны тапшыра:

эшмәкәрлек субъектының 59 пунктта каралган шартларның берәрсенә туры килүен раслаучы документларның күчермәләре;

биналары яки җир участоклары булуны раслый торган документларның күчермәләре;

проектны тормышка ашыру өчен кирәкле гамәлдәге контрактларның (булганда) күчермәләре;

лицензияләр һәм рөхсәт язуларының, патентлар, фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләренең, эксперт бәяләмәләренең һәм башкаларның (булганда) күчермәләре;

әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасы нигезендә бизнес-проект паспорты.

64. Әлеге бүлек таләпләре нигезендә субсидия алуга дәгъва иткән эшмәкәрлек субъекты әлеге Тәртипнең 37 пунктында каралган тәртиптә, Вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

милеккә товар сатып алуны раслаучы документларның күчермәләре һәм (яки) хезмәтләр күрсәтүне раслаучы документларның күчермәләре (товар һәм (яки) хезмәтләр бәясен чит ил валютасында түләп, чит ил оешмасы белән төзелгән килешүләрнең күчермәләрен тапшырган очракта, күрсәтелгән килешүнең рус телендәге вариантын, шулай ук түләү көненә сатып алынган җиһазның тулы бәясен Россия Федерациясенең Үзәк банкы курсы буенча сумнарда күрсәтеп, гариза бирүченең җитәкчесе тарафыннан төзелгән һәм имзаланган белешмәне теркәргә кирәк);

түләү турында банк билгесе куелган түләү йөкләмәләренең һәм, товар һәм (яки) хезмәтләргә тулысынча түләүне раслаучы башка документларның күчермәләре (чит ил валютасында түләгән очракта, исәп-хисап счетын, бенефициар банкын һәм товарлар һәм (яки) хезмәтләр бәясен тулысынча түләүне күрсәтеп, валюта күчерү буенча банк билгесе куелган банк документларының тулы исемлеген тапшырырга кирәк);

товар накладноеның, товарларны кабул итү-тапшыру актының яки башкарылган эшләр актының күчермәләре;

гариза бирүченең җитәкчесе тарафыннан расланган форма буенча, товарларны балансka куюны раслаучы бухгалтерлык документлары (бухгалтерлык хисабын алып баручы эшмәкәрлек субъектлары өчен);

товарлар һәм (яки) хезмәтләр сатып алу һәм тулысынча түләү фактын раслаучы керемнәр һәм чыгымнар исәбен алу кенәгәсе («Бухгалтерлык хисабы турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә бухгалтерлык хисабын алып бармый торган эшмәкәрлек субъектлары өчен);

гариза бирүченең әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында каралганча, моңа вәкаләт бирелгән зат имзасы һәм эшмәкәрлек субъекты мөһере белән таныкланган (юридик затлар өчен) (Россия Федерациясе законнарында мөһер булдыру бурычы билгеләнгән очракларда) яки үз кулы белән таныкланган (шәхси эшмәкәрләр өчен) гарантия хаты.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева

Яр Чаллы моношәһәренең җиһазлар лизингын һәм социаль эшмәкәрлекне үстерү чаралары кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу һәм субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү тәртибенә 1 нче кушымта

Чара буенча субсидия алуга
гариза

(җиһазлар лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының җиһазлар лизингы («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») килешүе буенча беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарын субсидияләү, Татарстан Республикасының социаль эшмәкәрлеген үстерү)

| Т/с | Күрсәткечнең исеме | Гариза бирүченең мәгълүматлары |
|---|---|---|
| 1. | Катнашучының тулы исеме | |
| 2. | ИНН | |
| 3. | КПП | |
| 4. | ОГРН | |
| 5. | ОКПО | |
| 6. | Проектны тормышка ашыра торган эшчәнлек төре (ОКВЭД буенча икътисад эшчәнлеге төренең расшифровкаланган коды) | |
| 7. | Юридик адрес | |
| 8. | Фактик адрес | |
| 9. | Дәүләти теркәлү датасы | |
| 10. | Банк реквизитлары, шул исәптән шәхси/с, к/с, БИК | |
| 11. | Субсидия күчерелгән көннән башлап исәпләнә торган ел нәтиҗәләре буенча эшләүчеләрнең планда каралган саны (гариза бирү моментына эшләүчеләр санын исәпкә алып) | |
| 12. | Субсидия күчерелгән көннән башлап исәпләнә торган ел нәтиҗәләре буенча бюджет системасының барлык бюджетларына салым чигерүләренең планда каралган күләме (хезмәткәрләрнең иминият взносларын һәм НДФЛ түләвен кертеп) | |
| 13. | Продукция (товарлар, эшләр, хезмәтләр) сатудан планда каралган табыш | |
| 14. | Гариза бирүченең җитәкчесе (Ф.И.А.и., вазыйфасы, элемтә реквизитлары) | |
| 15. | Баш бухгалтер (Ф.И.А.и., элемтә реквизитлары) | |
| 16. | Проект җитәкчесе (Ф.И.А.и., вазыйфасы, элемтә реквизитлары) | |
| 17. | Җаваплы башкаручы (Ф.И.А.и., вазыйфасы, элемтә реквизитлары) | |
| 18. | E-mail | |

Моның белән раслыйм:

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә:

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты (кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү инфраструктурасы оешмасы) булып саналам;

- «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ санлы Федераль законның 14 маддәсенең 3 һәм 4 пунктларындагы таләпләргә туры киләм.

Барлык юллар да тутырылган булырга тиеш. Мәгълүматлар булмаган очракта сызык куела.

Гариза бирүченең
житәкчесе ____________ ____________

имза имзаның расшифровкасы

МУ

Шушының белән әлеге гаризадагы һәм минем тарафтан бирелгән башка документлардагы персональ мәгълүматларымны «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм ____________ тарафыннан эшкәртүгә ризалыгымны белдерәм. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм ____________ персональ мәгълүматларны системалаштырырга, тупларга, сакларга, ачыкларга (яңартырга, үзгәртергә), файдаланырга, таратырга (шул исәптән, өченче затларга бирергә), иясез калдырырга, блокировкаларга һәм юкка чыгарырга мөмкин.

Гариза бирүченең
житәкчесе ____________ ____________

имза имзаның расшифровкасы

МУ

Гаризаны формалаштыру моментына түбәндәгеләрне хәбәр итәбез:

эшчәнлекне муниципаль берәмлек территориясендә гамәлгә ашырам;

Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр, шулай ук мәҗбүри пенсия һәм медицина иминиятенә иминият взнослары буенча үтәлмәгән бурычларым юк;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән чаралар буенча элек алган ярдәмгә бәйле, шул исәптән акчалардан файдалану һәм максатчан күрсәткечләргә ирешү турында хисаплылык бирү буенча үтәлмәгән бурычларым юк.

Тапшырылган мәгълүматның дөреслеген раслыйбыз.

Гариза бирүченең
житәкчесе ____________ ____________

имза имзаның расшифровкасы

МУ

Яр Чаллы монокалаһәренең җиһазлар лизингын һәм социаль эшмәкәрлекне үстерү чаралары кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу һәм субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү тәртибенә 2 нче кушымта

ГАРАНТИЯ ХАТЫ

____________ шәһәре «__»_____ 20__ ел

Моның белән ________________________________________
(юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең Ф.И.А.и.)

__________________________________________________ нигезендә эш итүче
(вәкаләт бирүче документ)
______________________________________йөзендә, _____
(вәкаләтле затның вазыйфасы, Ф.И.А.и.) (субсидия бирү кагыйдәләренең исеме)

таләпләргә туры килүне, шул исәптән түбәндәге шартларга туры килүне РАСЛЫЙ:

гариза бирү моментына:

а) эшчәнлекне муниципаль берәмлек территориясендә гамәлгә ашыру;

б) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр, шулай ук мәҗбүри пенсия һәм медицина иминиятенә иминият взнослары буенча үтәлмәгән бурычлар булмау;

в) әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән чаралар буенча элек алган ярдәмгә бәйле, шул исәптән акчалардан файдалану һәм максатчан күрсәткечләргә ирешү турында хисаплылык бирү буенча үтәлмәгән бурычлар булмау;

субсидия бирүгә килешү төзү планлаштырыла торган айдан соң килүче айның беренче числосына:

а) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үтәлү срогы җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр, шулай ук мәҗбүри пенсия һәм медицина иминиятенә иминият взнослары буенча үтәлмәгән бурычлар булмау;

б) Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурыч һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты каршында срогы чыккан башка бурыч булмау;

в) үзгәртеп оештырылу, ликвидацияләнү, банкротлык процессында булмау һәм хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләр булмау;

г) әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән чаралар буенча, башка норматив хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акчалар алынмау.

Гариза бирүченең
җитәкчесе

______________________ ______________________________

имза имзаның расшифровкасы

МУ

Яр Чаллы моношәһәренең җиһазлар лизингын һәм социаль эшмәкәрлекне үстерү чаралары кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу һәм субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү тәртибенә 3 нче кушымта

# Проект паспорты

түбәндәге чарада катнашкан очракта тутырыла:
Җиһазлар лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының җиһазлар лизингы («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») килешүе буенча беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарын субсидияләү

## 1. Төп өлеш

| | | |
|---|---|---|
| 1.1 | Гариза бирүченең тулы исеме | ________________ |
| 1.2 | Тәкъдим ителә торган проектның исеме | ________________ |
| 1.3 | Проектның һәм аның максатларының кыскача тасвирламасы (нәрсә житештерү, яңалык, проект нәтиҗәләрен конкрет куллану, файдалану перспективалары һәм башкалар турында 150 сүздән артмаган күләмдә) | ________________<br>________________<br>________________<br>________________ |

1.4 Проектны тормышка ашыру бәясе турында мәгълүмат:

проектның тулы бәясе, сум ____________________

таләп ителә торган дәүләт ярдәменең күләме, сум ____________________

проектны финанслау чыганаклары (суммасы сумнарда күрсәтелгән кредитлар, заемнар, шәхси акчалар) ____________________

1.5 Сатып алына торган җиһаз (исеме, маркасы, моделе, чыккан елы күрсәтелә) ____________________

1.6 Гариза бирүченең категориясе ____________________

## 2. Проектның икътисадый потенциалы

2.1 Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының субсидия бирү турында килешү төзегән көннән исәпләнә торган ел йомгаклары буенча, проектны тормышка ашыруның планлаштырылган нәтиҗәләре:

| | Күрсәткечнең исеме | Гариза биргән көннән исәпләнә торган узган ел *(гамәлдәге эшмәкәрлек субъектлары өчен)* | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының субсидия бирү турында килешү төзү елы | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының субсидия бирү турында килешү төзегән елдан соң килүче ел |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Сату күләменең акчала чагылышы, сум | | | |
| 2. | Сату күләменең натуралата чагылышы, данә, тн, кг һәм башкалар | | | |
| 3. | Продукция бәрәмлеген сату бәясе, сум | | | |
| 4. | Продукция житештерү һәм аны сату буенча барлык чыгымнар, сум | | | |
| | шул исәптән: | | | |
| | чимал сатып алу | | | |
| | хезмәт хакы түләү фонды | | | |
| | башкалар (иминиятләштерүгә, сертификатлаштыруга һәм башкаларга чыгымнар) | | | |
| 5. | Продукция житештерү һәм аны сатудан табыш, сум (керемнәр минус чыгымнар) | | | |
| 6. | Чиста табыш, сум | | | |
| 7. | Бюджет системасының барлык дәрәҗәдәге бюджетларына салым чигерүләренең күләме (иминият взносларын кертеп), сум | | | |
| 8. | Эшләүче кешеләр саны | | | |

2.2 Проектны тормышка ашыруның максатчан күрсәткечләре (субсидия алган елдан соң килүче ел нәтиҗәләре буенча):

**Игътибар!** Субсидия алган елдан соң килүче ел нәтиҗәләре буенча, паспортның әлеге пунктындагы күрсәткечләргә ирешмәү, гамәлдәге законнар нигезендә субсидия суммасын кире кайтаруга сәбәп була.

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Эшләүчеләр саны (гариза бирү моментына эшләүчеләр санын исәпкә алып), кеше | |
| 2. | Бюджет системасының барлык дәрәҗәдәге бюджетларына салым чигерүләренең күләме (иминият взносларын кертеп), сум | |
| 3. | Продукция (товарлар, эшләр, хезмәтләр) сатудан табыш, сум | |

## 3. Проектны тормышка ашыру план-графигы

| Айлар / Проектны тормышка ашыру этаплары | I | II | III | IV | V | VI | VII | VIII | IX | X | XI | XII |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |

## 4. Проект маркетингы

4.1 Чимал, материаллар һәм комплектлаштыручы эшләнмәләр базарына анализ

| Кирәкле чимал, материаллар һәм комплектлаштыручы эшләнмәләр исемлеге | Куллану күләменең натуральта чагылышы, данә, тн, кг һәм башкалар | Бәясе, сум | Чимал, материаллар һәм комплектлаштыручы эшләнмәләр кайтаруга килешүләр булу, % |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

4.2 Үзер продукция сату турында мәгълүмат

| Житештерелә торган продукциянең исеме | Бар булган/потенциаль кулланучыларның исеме | Сату күләме, сум | Продукция сатуга килешүләр булу, +/- |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

4.3 Продукция сатуны өстерү

бәя сәясәте

кулланучы тарафыннан товар өчен түләүнең махсус шартлары

сәүдә агентларыннан файдалану

массакүләм мәгълүмат чаралары

күргәзмә-сатулар

почтадан файдалану

семинарлар, презентацияләр

гарантия һәм гарантия срогы беткәннән соң хезмәт күрсәтү һәм башкалар

Барлык юллар да тутырылган булырга тиеш. Мәгълүматлар булмаган очракта сызык куела.

Гариза бирүченең
житәкчесе ____________ ____________/
имза имзаның расшифровкасы

МУ

Яр Чаллы моношәһәренең җиһазлар лизингын һәм социаль эшмәкәрлекне үстерү чаралары кысаларында кечкенә һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу һәм субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү тәртибенә 4 нче кушымта

# Проект паспорты

түбәндәге чарада катнашкан очракта тутырыла:
социаль эшмәкәрлекне үстерүгә бәйле чыгымнарны субсидияләү

## 1. Төп өлеш

| | | |
|---|---|---|
| 1.1 | Гариза бирүченең тулы исеме | |
| 1.2 | Тәкъдим ителә торган проектның исеме | |
| 1.3 | Проектның һәм аның максатларының кыскача тасвирламасы (нәрсә житештерү, яңалык, проект нәтиҗәләрен конкрет куллану, файдалану перспективалары һәм башкалар турында 150 сүздән артмаган күләмдә) | |

1.4 Проектны тормышка ашыру бәясе турында мәгълүмат:

проектның тулы бәясе, сум

таләп ителә торган ярдәм күләме, сум

проектны финанслау чыганаклары (суммасы сумнарда күрсәтелгән кредитлар, заемнар, шәхси акчалар)

1.5 Чыгым юнәлешләренә тасвирлама (товарның һәм (яки) хезмәтнең исеме, төп характеристикалары күрсәтелә)

1.6 Гариза бирүченең категориясе

## 2. Проектның икътисадый потенциалы

2.1 Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының субсидия бирү турында килешү төзегән көннән исәпләнә торган ел йомгаклары буенча, проектны тормышка ашыруның планлаштырылган нәтиҗәләре:

| | Күрсәткечнең исеме | Гариза биргән көннән исәпләнә торган узган ел (гамәлдәге эшмәкәрлек субъектлары өчен) | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының субсидия бирү турында килешү төзү елы | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының субсидия бирү турында килешү төзегән елдан соң килүче ел |
|---|---|---|---|---|
| 1. | 12 ай йомгаклары буенча продукция чыгару хезмәтләр күрсәтү күләме (натуралата чагылышта) | | | |
| 2. | Үзер продукция бәрәмлегеи сату бәясе | | | |
| 3. | Продукция (товарлар, эшләр, хезмәтләр) сатудан табыш | | | |
| 4. | Продукция житештерү һәм аны сату буенча барлык чыгымнар, сум | | | |
| | чимал сатып алу | | | |
| | хезмәт хакы түләү фонды, шул исәптән: | | | |
| | Тәртиинен 8.3.1 пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү фонды | | | |
| | башкалар (иминиятләштерүгә, сертификатлаштыруга һәм башкаларга чыгымнар) | | | |
| 5. | Продукция житештерү һәм аны сатудан табыш, сум (керемнәр минус чыгымнар) | | | |
| 6. | Чиста табыш, сум | | | |
| 7. | Бюджет системасының барлык дәрәҗәдәге бюджетларына салым чигерүләренең күләме (иминият взносларын кертеп), сум | | | |
| 8. | Эшләүчеләрнең гомуми саны, шул исәптән: | | | |
| 9. | Тәртиинен 8.3.1 пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләр саны | | | |

2.2 Проектны тормышка ашыруның максатчан күрсәткечләре (субсидия алган елдан соң килүче ел нәтиҗәләре буенча):

**Игътибар!** Субсидия алган елдан соң килүче ел нәтиҗәләре буенча, паспортның әлеге пунктындагы күрсәткечләргә ирешмәү, гамәлдәге законнар нигезендә субсидия суммасын кире кайтаруга сәбәп була.

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Эшләүчеләр саны (гариза бирү моментына эшләүчеләр санын исәпкә алып), кеше, шул исәптән | |
| 2. | Бюджет системасының барлык дәрәҗәдәге бюджетларына салым чигерүләренең күләме (иминият взносларын кертеп), сум | |
| 3. | Продукция (товарлар, эшләр, хезмәтләр) сатудан табыш, сум | |

## 3. Проектны тормышка ашыру план-графигы

| Айлар / Проектны тормышка ашыру этаплары | I | II | III | IV | V | VI | VII | VIII | IX | X | XI | XII |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |

## 4. Бизнес-проект юнәлеше*

| | | Кирәклесен билгеләргә |
|---|---|---|
| Сәламәтлек саклау өлкәсе, шул исәптән, аутсорсинг хезмәтләре | 10 балл | |
| Мәгариф, мәдәният өлкәсе | 10 балл | |
| Физик культура һәм спорт өлкәсен үстерү | 9 балл | |
| Балалар һәм яшьләр өчен түгәрәкләрдә, секцияләрдә, студияләрдә дәресләр оештыру | 9 балл | |
| Туризм, эшкә урнаштыру | 7 балл | |
| Халыкка конкурент һәм социаль хезмәтләр күрсәтү | 5 балл | |
| Башкалар | 0 балл | |

5. Максатчан билгеләнеш*

Кирәклесен билгеләргә

| | | |
|---|---|---|
| Техника һәм җиһаз сатып алу | 10 балл | |
| Махсус инвентарь сатып алу | 9 балл | |
| Оргтехника һәм программа чаралары сатып алу | 8 балл | |
| Производство проектлаштыруы, дизайн һәм башка эшләнмәләр | 7 балл | |
| Сертификатлаштыру һәм стандартлаштыру | 7 балл | |
| Бизнес-проект юнәлеше белән бәйле персоналны укыту һәм әзерләү | 5 балл | |

6. Халыкның социаль яклау ителмәгән төркемнәреннән хезмәткәрләр булу*:

Кирәклесен билгеләргә

| | | |
|---|---|---|
| Эшмәкәрлек субъектлары хезмәткәрләре арасыннан инвалидлар; 3 яшькә кадәрге балалары булган аналар; азат ителгән моменттан ике ел эчендә җәза үтәү урыннарыннан азат ителгән затлар; запастагы хәрби хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны кимендә 90 процент тәшкил итә | 10 балл | |
| Эшмәкәрлек субъектлары хезмәткәрләре арасыннан инвалидлар; 3 яшькә кадәрге балалары булган аналар; азат ителгән моменттан ике ел эчендә җәза үтәү урыннарыннан азат ителгән затлар; запастагы хәрби хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны кимендә 75 процент тәшкил итә | 5 балл | |
| Эшмәкәрлек субъектлары хезмәткәрләре арасыннан инвалидлар; 3 яшькә кадәрге балалары булган аналар; азат ителгән моменттан ике ел эчендә җәза үтәү урыннарыннан азат ителгән затлар; запастагы хәрби хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны кимендә 50 процент тәшкил итә | 0 балл | |

7. Булдырыла торган эш урыннарының саны*:

Кирәклесен билгеләргә

| | | |
|---|---|---|
| 5 тән артык эш урыны булдыру | 10 балл | |
| 3 тән 5 кә кадәр эш урыны булдыру | 7 балл | |
| 3 кә кадәр эш урыны булдыру | 5 балл | |
| Яңа эш урыннары булдыру каралмаган | 0 балл | |

8. Салым түләүләренең күләме*:

| | | Кирәклесен билгеләргә |
| --- | --- | --- |
| Салым чигерүләре субсидия суммасын 3 елга кадәр срокта каплый | 10 балл | |
| Салым чигерүләре субсидия суммасын 3 елдан 5 елга кадәр срокта каплый | 7 балл | |
| Салым чигерүләре субсидия суммасын 5 елдан 7 елга кадәр срокта каплый | 6 балл | |
| Салым чигерүләре субсидия суммасын 7 елдан арткан срокта каплый | 1 балл | |

9. Хезмәткәрләрнең уртача хезмәт хакы*:

| | | Кирәклесен билгеләргә |
| --- | --- | --- |
| Уртача хезмәт хакы дәрәҗәсе 3 минималь хезмәт хакы күләменнән югары | 10 балл | |
| Уртача хезмәт хакы дәрәҗәсе 2 дән 3 кә кадәр минималь хезмәт хакы күләмендә | 5 балл | |
| Уртача хезмәт хакы дәрәҗәсе 1 дән 2 гә кадәр минималь хезмәт хакы күләмендә | 3 балл | |
| Уртача хезмәт хакы дәрәҗәсе 1 минималь хезмәт хакы күләменнән түбән | 0 балл | |

10. Проектны тормышка ашыруның техник мөмкинлекләре (биналар, технологик тоташу, таләп ителгән куәтләр) булу*:

| | | Кирәклесен билгеләргә |
| --- | --- | --- |
| Техник мөмкинлекләр булу | 10 балл | |
| Гариза биргән моментка техник мөмкинлекләр булмау | 0 балл | |

11. Проектның маркетинг эшләнеше (үзер продукцияне сату каналлары булу)*:

| | | Кирәклесен билгеләргә |
| --- | --- | --- |
| Үзер продукция сатуга килешүләр булу | 10 балл | |
| Үзер продукция сатып алу нияте турында килешүләр булу | 7 балл | |
| Үзер продукциянең потенциаль сатып алучылары булу | 5 балл | |
| Сату каналлары билгеләнмәгән | 0 балл | |

* - таблицаның берничә пунктына туры килгән очракта, исәпләү өчен, иң югары балл гына бер пункт кабул ителә.

12. Эшмәкәрлек субъектының шәхси акчалары түбәндәгене тәшкил итә:

| | Кирәклесен билгеләргә |
|---|---|
| Проект бәясенең 70-90 процентын | |
| Проект бәясенең 50-69 процентын | |
| Проект бәясенең 15-49 процентын | |

13. Тәртипнең 8.3.1 пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең саны

| | Кирәклесен билгеләргә |
|---|---|
| Инвалидлар | |
| Өлкән яшьтәге гражданнар (60 яшьтән өлкән ир-атлар һәм 55 яшьтән өлкән хатын-кызлар) | |
| 7 (җиде) яшькә кадәр балалары булган хатын-кызлар | |
| Ятимнәр | |
| Балалар йортыннан чыгарылучылар | |
| Конкурс гаризасы бирү датасыннан алда килгән 2 (ике) ел дәвамында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар | |

Максималь мөмкин булган баллар – 80 балл. Проектны Конкурс комиссиясе тарафыннан карап тикшерүгә чыгару өчен 16 балл җыярга кирәк.

4.3 Продукция сатуны оештыру
бәя сәясәте
кулланучы тарафыннан товар өчен түләүнең махсус шартлары
сәүдә агентларыннан файдалану
массакүләм мәгълүмат чаралары
күргәзмә-сатулар

| | |
|---|---|
| почтадан файдалану | |
| семинарлар, презентацияләр | |
| гарантия һәм гарантия срогы беткәннән соң хезмәт күрсәтү һәм башкалар | |

Барлык юллар да тутырылган булырга тиеш. Мәгълүматлар булмаган очракта сызык куела.

Гариза бирүченең житәкчесе ________________ / ________________________

имза — имзаның расшифровкасы

МУ

Яр Чаллы моношәһәренең җиһазлар лизингын һәм социаль эшмәкәрлекне үстерү чаралары кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу һәм субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү тәртибенә 5 нче кушымта

«______________________________________________»
(җиһазлар лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының җиһазлар лизингы («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») килешүе буенча беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарын субсидияләү, Татарстан Республикасының социаль эшмәкәрлеген үстерү)

чарасын тормышка ашыру максатында

эшләр башкаруга (товарлар җитештерүгә, хезмәтләр күрсәтүгә) бәйле

______________________________ өчен
(чыгымнарны каплау, чыгымнарны финанс белән тәэмин итү)

субсидия бирү турында килешү N __

____________ шәһәре «__» ________ 201_ ел

Бер яктан, ____________ нигезендә эш итүче ____________ йөзендә,
(вәкаләт бирүче документ) (вәкаләтле затның Ф.И.Атл., вазыйфасы)

бюджет акчаларын алучы буларак, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 маддәсе нигезендә субсидия бирүгә

бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән ______________________________.
(Башкарма хакимият органының исеме)

алга таба «Вәкаләтле орган» дип атала, икенче яктан, ______________ нигезендә эш итүче

________________________ йөзендә, ________________________.
(вәкаләтле затның Ф.И.А.и., вазыйфасы) (юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең Ф.И.А.и.)

алга таба «Алучы» дип атала, бергә «Яклар» дип аталучылар, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә ________________________
(Субсидия бирү тәртибенең исеме)

(алга таба - Субсидия бирү тәртибе), түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

I. Килешү предметы

1.1. Вәкаләтле орган Алучыга «________________________»

чарасын тормышка ашыру максатында эшләр башкаруга (товарлар житештерүгә, хезмәтләр күрсәтүгә) бәйле

________________________ өчен субсидия бирә, ә Алучы конкурста сайлап алуга тапшырылган
(чыгымнарны каплау, чыгымнарны финанс белән тәэмин итү)

документлар нигезендә ________________________ территориясендә бизнес-проектны
(муниципаль берәмлек)

тормышка ашырырга һәм бирелгән субсидия максатчан билгеләнеш буенча файдаланырга тиеш.

1.2. Субсидия «________________________» бизнес-проектын

тормышка ашыру өчен күчерелә.

1.3. Бирелә торган субсидия максатчан характерга ия һәм әлеге Килешүдә каралмаган максатларда файдаланыла алмый.

## 2. Субсидия бирүне финанс белән тәэмин итү

2.1. Субсидия әлеге Килешүдә күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчаларын алучы буларак Вәкаләтле органга житкерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларына туры китереп, түбәндәге күләмдә бирелә:

БК _______ коды буенча ____________ (______________________) сум.
(код БК) (сумма) (сумма сүзләр белән)

## 3. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

3.1. Субсидия күчерү Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла:

3.1.1. күчерелү срокларын һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрен исәпкә алып, субсидия бирү турында карар кабул ителгән һәм әлеге килешү төзелгән көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн срокта, Алучының ________________________________________
(Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесенең яки кредит оешмасының исеме)
ачылган счетына;

3.1.2. юридик затларга финанс белән тәэмин итү өчен субсидия бирелгән очракта, субсидия федераль бюджеттан күчерелгәндә, субсидия Алучының акча йөкләмәләрен түләү өчен документлары Алучы тарафыннан Федераль казначылык территориаль органына тапшырылган көннең икенче эш көненнән да калмый, Алучының Федераль казначылык территориаль органында ачылган шәхси счетына күчерелә;

3.2. Субсидия Алучының счетларына Вәкаләтле орган тарафыннан бер тапкыр күчерелә.

## 4. Якларның үзара эшчәнлеге

4.1. Вәкаләтле орган бурычлы:

4.1.1. әлеге Килешү шартлары нигезендә Субсидия бирүне тәэмин итәргә;

4.1.2. нәтиҗәлелек күрсәткечләрен (максатчан күрсәткечләрне) билгеләргә;

4.1.3. әлеге Килешү шартлары нигезендә тапшырылган һәм әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торучы әлеге Килешүнең 1 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча, нәтиҗәлелек күрсәткечләре (максатчан күрсәткечләр) зурлыгына ирешү турындагы хисап нигезендә, Алучы тарафыннан нәтиҗәлелек күрсәткечләренә (максатчан күрсәткечләргә) ирешүне бәяләргә;

4.1.4. Алучының әлеге Килешүнең 3.1 пунктына туры китереп күрсәтелгән счетына Субсидия күчерүне тәэмин итәргә;

4.1.5. планлы һәм (яки) планнан тыш тикшерүләр үткәрү юлы белән, субсидия бирү Тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү тәртибе, максатлары һәм шартларының Алучы тарафыннан үтәлешен контрольдә тотарга:

4.1.5.1. Вәкаләтле орган урнашкан урында;

4.1.5.2. Алучы урнашкан урында, Алучы тарафыннан башкарылган Субсидиядән файдалану белән бәйле операцияләрне документлар буенча һәм фактик анализ юлы белән;

4.1.6. субсидия бирү Тәртибендә һәм әлеге Килешүдә каралган Субсидия бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары Алучы тарафыннан бозылу факты (фактлары) Вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән яки дәүләт финанс контроле органыннан алар турында мәгълүмат алынган, шул исәптән әлеге Килешү нигезендә Алучы тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүматлар күрсәтелгән очракта, күрсәтелгән таләптә билгеләнгән күләмдә һәм срокларда Субсидияне муниципаль бюджетка кире кайтаруны тәэмин итү турындагы таләпне Алучыга җибәрергә;

4.1.7. Алучы тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәрне, документларны һәм башка мәгълүматны алган көннән соң 30 эш көне эчендә аларны карап тикшерергә һәм кабул ителгән карар турында Алучыга хәбәр итәргә (кирәк булганда);

4.1.8. Алучының мөрәҗәгатен алган көннән соң 30 эш көне эчендә әлеге Килешүне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча Алучыга аңлатмалар җибәрергә;

4.1.9. Россия Федерациясе бюджет законнары һәм субсидия бирү Тәртибе нигезендә башка йөкләмәләрне башкарырга.

4.2. Вәкаләтле орган хокуклы:

4.2.1. субсидия бирү Тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү тәртибе, максатлары һәм шартларының Алучы тарафыннан үтәлешен контрольдә тоту өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны Алучыдан сорап алырга;

4.2.2. Алучы тарафыннан субсидия бирү шартлары бозылган очракта субсидияне кире кайтару турында карар кабул итәргә;

4.2.3. Россия Федерациясе бюджет законнары һәм субсидия бирү Тәртибе нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

4.2.4. Вәкаләтле орган карамагында булган документлардагы мәгълүматларның дөреслеге нигезле шик тудырган, яисә бу мәгълүматлар Алучы тарафыннан әлеге Килешүдәге йөкләмәләр үтәлешен бәяләү мөмкинлеге бирмәгән очракта, Вәкаләтле орган бизнес-проектны фактик тормышка ашыру урынына барып тикшерү үткәрергә хокуклы.

4.3. Алучы бурычлы:

4.3.1. югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлаштыручы эшләнмәләр сатып алганда (кайтартканда), Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаларны бирү максатына ирешүгә бәйле башка операцияләрдән тыш, Субсидия хисабына чит ил валютасы сатып алмаска;

4.3.2. Субсидия хисабына гамәлгә ашырыла торган операцияләрнең аерымланган аналитик исәбен алып барырга;

4.3.3. тапшырылган документлар нигезендә ______________________ территориясендә бизнес-проектны тормышка ашырырга һәм бирелгән субсидияне максатчан билгеләнеш буенча файдаланырга;

4.3.4. субсидия алу өчен, Вәкаләтле органга дөрес булмаган яки фальсификацияләнгән документлар тапшырылган очракта, шулай ук хисап чоры нәтиҗәләре буенча бизнес-проектны тормышка ашыруның түбәндәге фактик күрсәткечләренә ирешмәгәндә:

а) эш урыннарының саны _____ берәмлек;

б) салым чигерүләре __________ сум;

в) сатудан табыш __________ сум

20% тан арткан очракта, Алучы әлеге Килешүдә күрсәтелгән субсидия суммасын кире кайтарырга бурычлы;

4.3.5. нәтиҗәлелек күрсәткечләре (максатчан күрсәткечләр) зурлыгына ирешү турында хисапны __________ кадәр срокта Вәкаләтле органга тапшырырга.

Хисап чоры __________.

Алучы әлеге Килешүнең 1 нче кушымтасы нигезендә бизнес-проектны тормышка ашыруга кагылышлы документларны (үзенең оештыру-хокукый формасы, шулай ук салым салу режимы нигезендә) хисапка терки.

4.3.6. Вәкаләтле органның соравы буенча, күрсәтелгән сорауны алган көннән соң 10 эш көне эчендә, әлеге Килешүнең 4.2.1. пункты нигезендә Субсидия бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны җибәрергә;

4.3.7. Вәкаләтле органнан әлеге Килешүнең4.1.6. пункты нигезендә таләп алган очракта:

4.3.7.1. күрсәтелгән таләптә билгеләнгән срокларда Субсидия бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары бозылу фактын (фактларын) бетерергә;

4.3.7.2. күрсәтелгән таләптә билгеләнгән күләмдә һәм срокларда Субсидияне муниципаль берәмлек бюджетына кире кайтарырга;

4.3.8. әлеге Килешү нигезендә Вәкаләтле органга бирелә торган мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итәргә;

4.3.9. Алучы бизнес-проектны тормышка ашыру мөмкин булмауны яисә башка сәбәпләр буенча аны гамәлгә ашыру максатчан булмауны ачыклау турында кичекмәстән язмача рәвештә Вәкаләтле органга хәбәр итәргә һәм 10 (ун) банк көне эчендә әлеге Килешүдә күрсәтелгән субсидия суммасын тулы күләмдә Вәкаләтле органның шәхси счетына кире кайтаруны гамәлгә ашырырга.

4.3.10. Алучының почта һәм банк реквизитлары, элемтә телефоны номерлары, гамәлгә куючылар һәм житәкче затларның составы үзгәргән, салым исәбенә куелу урыны үзгәргән, гамәлгә кую документларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән очракта, 10 (ун) эш көне эчендә бу хакта язмача рәвештә Вәкаләтле органга хәбәр итәргә.

4.3.11. Әлеге Килешү гамәлдә булу чорында ВЭД исемлегенә, гамәлгә ашырганда «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль закон нигезендә дәүләт ярдәме чаралары күрсәтү мөмкин булмаган эшчәнлек төрләрен кертүне рөхсәт итмәскә.

4.3.12. Хисап чорыннан соң килүче финанс елының 10 февраленә кадәр срокта, чираттагы финанс елының 1 гыйнварына торышы буенча, хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешен муниципаль берәмлек бюджетына кире кайтарырга.

Агымдагы финанс елында аларны шул ук максатлар өчен юллау ихтыяжы булу турында Вәкаләтле орган тарафыннан карар кабул ителмәүгә мөнәсәбәтле субсидиянең файдаланылмый калган өлеше кире кайтарылырга тиеш.

4.4. Алучы хокуклы:

4.4.1. Вәкаләтле органга әлеге Килешүгә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр юлларга;

4.4.2. әлеге Килешүне үтәү сәбәпле аңлатмалар алу максатында Вәкаләтле органга мөрәҗәгать итәргә;

4.4.3. Россия Федерациясе бюджет законнары һәм субсидия бирү Тәртибе нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Әлеге Килешүне үтәү сәбәпле Яклар арасында килеп чыккан бәхәсләр, мөмкинлектән чыгып, тиешле беркетмәләр яки башка документлар рәсмиләштереп, сөйләшүләр үткәрү юлы белән үзара хәл ителә. Ризалашуга ирешмәгән очракта, Яклар арасындагы бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

6.2. Әлеге Килешү Якларның һәрберсе исеменнән эш итү хокукына ия затлар тарафыннан имзаланган, ләкин әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын житкерүдән иртәрәк булмаган датадан үз көченә керә һәм Яклар әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен тулысынча үтәгәнче гамәлдә була.

6.3. Әлеге Килешүне, шул исәптән әлеге Килешүнең 4.2.1 пунктындагы нигезләмәләр нигезендә үзгәртү Якларның ризалыгы буенча һәм әлеге Килешүгә өстәмә килешенү рәвешендә рәсмиләштерелә.

6.4. Әлеге Киләшүне өзү түбәндәге очракларда мөмкин:

6.4.1. Алучының эшчәнлеге үзгәртеп оештырылу яки туктатылу;

6.4.2. субсидия бирү Тәртибендә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары Алучы тарафыннан бозылу;

6.4.3. Якларның үзара килешенүе буенча.

6.5. Әлеге Килешүне берьяклы тәртиптә өзү Алучы тарафыннан әлеге Килешүдә билгеләнгән нәтижәлелек күрсәткечләренә (максатчан күрсәткечләргә) яки әлеге Килешүдә билгеләнгән башка күрсәткечләргә ирешмәгән очракта мөмкин.

6.6. Әлеге Килешүне имзалап, субсидия Алучы «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, әлеге Килешүне үтәү максатында әлеге Килешүдәге һәм ул Вәкаләтле органга тапшырган теләсә кайсы башка документлардагы персональ мәгълүматларны Вәкаләтле орган тарафыннан эшкәртүгә үз ризалыгын белдерә. Югарыда күрсәтелгән федераль закон кысаларында Вәкаләтле орган субсидия Алучының персональ мәгълүматларын системалаштырырга, тупларга, сакларга, ачыкларга (яңартырга, үзгәртергә), файдаланырга, таратырга (шул исәптән, өченче затларга бирергә), нисез калдырырга, блокировкаларга һәм юкка чыгарырга хокуклы. Вәкаләтле

орган персональ мәгълүматларны эшкәрткәндә. Вәкаләтле орган ихтыяры буенча автоматлаштырылган, механик, кулдан һәм башка ысулны файдаланырга хокуклы.

6.7. Әлеге Килешүне имзалап, субсидия Алучы Вәкаләтле орган, дәүләт (муниципаль) идарә органнары һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан субсидия Алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә үз ризалыгын белдерә.

6.8. Әлеге Килешү Яклар тарафыннан һәр Якларның һәрберсенә берәр нөсхә итеп, кәгазь документ формасында ике нөсхәдә төзелде.

## 7. Якларның юридик адреслары һәм реквизитлары

_____ ___ ел № __
Килешүгә 1 нче кушымта

“___________________________________________________”
(җиһазлар лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының җиһазлар лизингы («ЛИЗИНГ-ГРАНТ»)
килешүе буенча беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарын субсидияләү, Татарстан Республикасының социаль эшмәкәрлеген үстерү)

чарасы буенча бизнес-проектның исеме:

“___________________________________________________”

бизнес-проектны тормышка ашыру буенча
НӘТИҖӘЛЕЛЕК КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ (МАКСАТЧАН КҮРСӘТКЕЧЛӘР) ЗУРЛЫКЛАРЫНА ИРЕШҮ ТУРЫНДА ХИСАП

Бизнес-проектны тормышка ашыру йомгаклары буенча мәгълүмат:

| Күрсәткечнең исеме | Зурлыгы (план) | Зурлыгы (факт) | Кире кагу, % |
|---|---|---|---|
| Эш урыннары саны, берәмлек | | | |
| Барлык дәрәҗәдәге бюджетларга һәм дәүләт бюджеттан тыш фондлар бюджетларына түләнгән барлык салым түләүләре, сум | | | |
| Продукция (товарлар, эшләр, хезмәтләр) сатудан табыш, сум | | | |

Хисапка түбәндәге раслаучы документларның тиешле рәвештә таныкланган күчермәләре теркәлә:

1. Вәкаләтле орган тарафыннан таныкланган бизнес-проектны тормышка ашыру чоры өчен бухгалтерлык хисаплылыгы (бухгалтерлык балансы һәм финанс нәтиҗәләре турында хисап яки керемнәр һәм чыгымнар кенәгәсе).

2. Вәкаләтле орган тарафыннан таныкланган, бизнес-проектны тормышка ашыру чоры өчен кулланыла торган салым салу системасына бәйле рәвештә барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым хисаплылыгы (оешмалар милкәтенә салым, иминият взнослары, транспорт салымы, җир салымы, физик затлар керемнәренә салым, физик затлар милкәтенә салым), шулай ук:

2.1. Гомуми салым салу системасын кулланганда:

- оешмалар табышына салым буенча салым декларациясе;

- өстәлгән кыйммәткә салым буенча салым декларациясе.

2.2. Гадиләштерелгән салым салу системасын кулланганда:

- гадиләштерелгән салым салу системасын куллану сәбәпле түләнә торган салым буенча салым декларациясе.

2.3. Бердәм авыл хуҗалыгы салымын кулланганда:

- Бердәм авыл хуҗалыгы салымы буенча салым декларациясе.

2.4. Йөкләтелгән керемгә бердәм салымны кулланганда:

- эшчәнлекнен аерым төрләре өчен йөкләтелгән керемгә салым буенча салым декларациясе.

2.5. Салым салуның патент системасын кулланганда:

- салым салынуның патент системасында түләнә торган салым буенча салым декларациясе.

2.6. Салым түләү фактын раслаучы документлар (түләү йөкләмәсе һәм (яки) салым түләү турында квитанция).

2.7. Салым органыннан РФ законнары һәм РТ законнары нигезендә РФ бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү буенча эшмәкәрлек субъектының үтәлмәгән йөкләмәләре булмауны раслаучы, йомгаклау хисабы бирү аеның бер датасы торышына бирелгән һәм билгеләнгән тәртиптә таныкланган белешмә.

3. Физик затларга түләүне һәм башка бүләкләүләрне башкаручы иминият взнослары түләүчеләр тарафыннан Россия Федерациясе Пенсия фондына мәҗбүри пенсия иминияте һәм Федераль мәҗбүри медицина иминияте фондына мәҗбүри медицина иминияте өчен исәпләнгән һәм түләнгән иминият взнослары буенча исәп-хисап. Йомгаклау хисабы бирү моментына, физик затларга түләүне һәм башка бүләкләүләрне башкаручы иминият взнослары түләүчеләр тарафыннан Россия Федерациясе Пенсия фондына мәҗбүри пенсия иминияте һәм Федераль мәҗбүри медицина иминияте фондына мәҗбүри медицина иминияте өчен иминият взнослары түләү фактын раслаучы документлар (түләү йөкләмәсе һәм (яки) салым түләү турында квитанция).

4. Вакытлыча эшкә яраксызлык очрагында мәҗбүри социаль иминият өчен, ана булу сәбәпле һәм, производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәргә бәйле авырулардан мәҗбүри социаль иминият буенча, шулай ук бизнес-проектны тормышка ашыру чорында иминият тәэмин ителеше өчен түләү чыгымнары буенча исәпләнгән һәм түләнгән иминият взнослары

буенча исәп-хисап. Вакытлыча эшкә яраксызлык очрагында мәҗбүри социаль иминият өчен, ана булу сәбәпле һәм производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәргә бәйле авырулардан мәҗбүри социаль иминият буенча, шулай ук бизнес-проектны тормышка ашыру чорында иминият тәэмин ителеше өчен түләү чыгымнары буенча иминият взносларын түләү фактын раслаучы документлар (түләү йөкләмәсе һәм (яки) түләү турында квитанция).

5. Бизнес-проектны тормышка ашыру кысаларында хезмәткәрләр белән төзелгән хезмәт килешүләре.

6. Проектны тормышка ашыру чоры өчен эшләүчеләрнең исемлек буенча уртача саны турында вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән белешмә.

7. Җиһазны финанс арендасына (лизингка) бирү килешүе буенча түләүләрне түләүгә бәйле чыгымнарны өлешчә финанслау өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына субсидия бирү турында төзелгән килешү күчермәсе.

8. «Җиһазлар лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының җиһазлар лизингы («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») килешүе буенча беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарын субсидияләү» чарасы буенча субсидия алучы өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

Төп параметрлар күрсәтелгән лизинг килешүе:

Лизинг килешүе буенча Лизингка бирүчегә аванс күчерелү турында түләү йөкләмәсенең (түләү турында банк билгесе куелган) күчермәсе:

Лизинг түләүләрен үз вакытында түләүне раслаучы түләү йөкләмәләренең (түләү турында банк билгесе куелган) күчермәләре:

Финанс арендасы (лизинг) килешүе буенча җиһазны кабул итү-тапшыру акты. Җиһаз килешү предметы булып торган очракта, эксплуатациягә кертү актын яки кабызу-көйләү актын, шулай ук завод номеры күрсәтелгән җиһаз паспортын, транспорт чарасы булса - транспорт чарасының паспортын теркәргә кирәк. Йомгаклау хисабын бирү моментына лизинг килешүе буенча йөкләмәләр үтәлеше турында белешмә һәм (яки) лизинг килешүе буенча лизинг компаниясе белән исәп-хисапларны чагыштыру акты.

9. «Татарстан Республикасының социаль эшмәкәрлеген үстерү» чарасы буенча субсидия алучы өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

Милеккә товар (техника, җиһаз, махсус инвентарь, оргтехника) сатып алуга төзелгән килешүләр (чит ил валютасында түләп, товар сатып алуга чит ил оешмасы белән төзелгән килешүләрнең күчермәләрен тапшырган очракта, күрсәтелгән килешүнең рус телендәге вариантын, шулай ук түләү көненә сатып алынган җиһазның тулы бәясен Россия Федерациясенең Үзәк банкы курсы буенча сумнарда күрсәтеп, гариза бирүченең җитәкчесе тарафыннан төзелгән һәм имзаланган белешмәне теркәргә кирәк);

Түләү турында банк билгесе куелган түләү йөкләмәләре һәм товарның тулы бәясен түләүне раслаучы башка документлар (чит ил валютасында түләгән очракта, исәп-хисап счетын, бенефициар банкын һәм товарлар бәясен тулысынча түләүне күрсәтеп, валюта күчерү буенча банк билгесе куелган банк документларының тулы исемлеген тапшырырга кирәк);

Товар накладнойлары яки товарларны кабул итү-тапшыру акты;

Гариза бирүченең җитәкчесе тарафыннан расланган форма буенча, товарларны балanska куюны раслаучы бухгалтерлык документлары (бухгалтерлык хисабын алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен);

Товарлар сатып алу һәм тулысынча түләү фактын раслаучы керемнәр һәм чыгымнар исәбен алу кенәгәсе («Бухгалтерлык хисабы турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә бухгалтерлык хисабын алып бармый торган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен).

Субсидия алучының элемтә мәгълүматлары: (Ф.И.А.и., вазыйфасы, тел, e-mail)

______________________________________________________________

Субсидия алучы ____________ /________________/

(имза) (имзаның расшифровкасы)

МУ

Йомгаклау хисабын тапшырды: (Ф.И.А.и., вазыйфасы, ышаныч язуы №, тел., e-mail):

______________________________________________________________

____________ /________________/

(имза) (имзаның расшифровкасы)